**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) 42-51-76, тел.42-42-66

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр12
факс (8555) 42-51-76, тел.42-42-66

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү турында**

Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы системасын камилләштерү максатларында Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ**:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 6 нчы номерлы карарының 1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«- 18 нче кушымта нигезендә квартал саен бирелә торган премияләр һәм башка түләүләр күләме”.

2. Бюджеттан финанслана торган Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге карарның 1нче пункты нигезендә Түбән Кама шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең акчалата түләүләрен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э. Р. Долотказинага йөкләргә

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2014 елның 2 сентябре
20 номерлы карарына
**кушымта**

Түбән Кама шәһәре Советының
2009 елның 28 гыйнвары
6 номерлы карарына
**18 кушымта**

**Квартал саен бирелә торган премияләрнең
һәм башка түләүләрнең күләме**

Квартал саен бирелә торган премия һәм башка түләүләр күләме хезмәт хакының (акчалата керем) бер айлык уртача күләменнән артмаган күләмдә билгеләнә. Түләү җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты нигезендә Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р.Долотказина